ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**02.11.2024**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 4152**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне уздыру буенча иҗтимагый совет турындагы нигезләмәне раслау хакында

2017 елның 5 декабрендәге «Мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә оешмалар һәм медик-социаль экспертиза федераль учреждениеләре тарафыннан хезмәт күрсәтүләр сыйфатына бәйсез бәя бирүне камилләштерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 392-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының мәдәният һәм мәгариф өлкәсендәге оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтүләр сыйфатын яхшырту максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне уздыру буенча иҗтимагый совет турындагы нигезләмәне кушымтада бирелгән тәртиптә расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

- 2019 елның 04 мартындагы «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне уздыру буенча иҗтимагый совет турындагы нигезләмәне раслау турында» 537 номерлы;
-2019 елның 04 сентябрендәге «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне уздыру буенча иҗтимагый совет турындагы нигезләмәне раслау турында» 2019 елның 04 мартындагы 537 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 1800 номерлы.

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җитәкче З.Ф.Хәбибуллин

РАСЛАНДЫ
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 2 ноябрендәге
4152 номерлы карары белән

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне уздыру буенча иҗтимагый совет турындагы
НИГЕЗЛӘМӘ

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет (алга таба – Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет)Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы киңәшмә органы булып тора, ул Зеленодольск муниципаль районында гражданнарның мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфаты, аларның эшчәнлеген камилләштерү турында мәгълүматтан файдалану хокукын гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләрне карый, шулай ук әлеге нигезләмәдә каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

1.2. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституцион законнар, федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм боерыклары, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары һәм боерыклары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Рәисе указлары һәм боерыклары, Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарлары һәм боерыклары, муниципаль хокукый актлар, шулай ук әлеге нигезләмәгә таяна.

1.3. Мәдәният, мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтүләр сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен үз эченә алган Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет карары һәм аларның эшчәнлеген яхшырту буенча тәкъдимнәр, кергән көннән алып, бер ай эчендә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитет тарафыннан мәҗбүри рәвештә каралырга, мәдәният, мәгариф өлкәсендә оешмаларның эшчәнлеген камилләштерү буенча чаралар эшләгәндә һәм аларның җитәкчеләре эшчәнлеген бәяләгәндә исәпкә алынырга тиеш.

1.4. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзалары үз эшчәнлекләрен җәмәгать башлангычларында алып баралар.

1.5. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет гражданлык җәмгыяте институтлары, дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренең үзара кызыксынуы нигезендә үз эшен гамәлгә ашыра .

1.6. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет эшчәнлеге турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба - «Интернет» челтәре) Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының http://zelenodolsk.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

1.7. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет турындагы нигезләмә күрсәтелгән Иҗтимагый совет төзелгән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

## 2. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның максатлары, бурычлары һәм вәкаләтләре

2.1. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет эшчәнлегенең төп максатлары түбәндәгеләр:

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан муниципаль мәдәният һәм мәгариф оешмалары, башка оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү һәм муниципаль берәмлек бюджетларының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүчеләр шартларының сыйфатына иҗтимагый контрольне көчәйтү;
- тиешле өлкәдә ачыклык, законлылык һәм профессионализм принципларын үстерү.

2.2. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

- мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатына бәйсез бәя бирү;
- мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар эшчәнлеген камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;
- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарлар кабул иткәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу механизмын камилләштерү;
- мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтүнең сыйфаты турында җәмәгатьчелекнең хәбәрдарлыгын арттыру.

2.3. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет үзенә йөкләнгән бурычлар чикләрендә:

- сыйфатны бәйсез бәяләү үткәрелә торган оешмалар исемлеген билгели;
- эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу турында документ проектларын, шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитет белән мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары турында мәгълүмат җыю һәм гомумиләштерүне гамәлгә ашыра торган оешма (алга таба - оператор) белән төзелә торган дәүләт контракты проектын карауда катнаша;
- оператор биргән мәгълүматны исәпкә алып, мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатына бәйсез бәя бирә;
- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитетына мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен, шулай ук аларның эшчәнлек сыйфатын яхшырту турындагы тәкъдимнәрне тапшыра.

## 3. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет составы

3.1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Иҗтимагый советы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты мөрәҗәгате буенча, әлеге мөрәҗәгать кабул ителгән көннән соң, бер айдан да соңга калмыйча, сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет төзи һәм аның составын раслый.

3.2. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет
гражданнар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау максатыннан оештырылган иҗтимагый оешмалар, инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре вәкилләре арасыннан төзелә.

3.3. Күрсәтелгән Иҗтимагый совет белән муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан һәм муниципаль берәмлек бюджетларының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән муниципаль мәдәният һәм мәгариф оешмалары һәм мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче башка оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартларының сыйфатына бәйсез бәя бирелә.

3.4. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Иҗтимагый советы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитетына әлеге органнар каршында төзелгән Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет составы турында хәбәр итә.

3.5. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты, Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет бәйсез бәя үткәрү буенча Иҗтимагый совет составы расланган көннән соң, 30 календарь көннән дә соңга калмыйча,Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның беренче утырышын оештыра, анда аның әгъзалары арасыннан Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисе һәм рәис урынбасары сайлана. Карар ачык тавыш бирү юлы белән Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

3.6. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисен яисә рәис урынбасарын вазыйфасыннан азат итү мәсьәләсе Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Иҗтимагый советы рәисе, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе мөрәҗәгате буенча, шулай ук Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисе яки рәис урынбасарының шәхси гаризасы яисә Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет  әгъзаларының гомуми саныннан кимендә биштән бер өлешен тәшкил иткән Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет төркеме тәкъдиме буенча Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет тарафыннан карала. Карар Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

3.7. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисе Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзалары арасыннан Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча җаваплы секретарьне билгели.

3.8. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның  составы өч елга раслана.

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советны  яңа срокка төзегәндә, составының өчтән бер өлеше үзгәртелә.

3.9. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет составына бәйсез бәяләү буенча түбәндәге вәкилләр керә алмый:

- дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары;
- мәдәният һәм мәгариф өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы иҗтимагый берләшмәләр;
- мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә эшчәнлек алып баручы оешмалар җитәкчеләре (аларның урынбасарлары) һәм хезмәткәрләре.

3.10. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет үз эшенә мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә эшчәнлек алып баручы иҗтимагый берләшмәләр һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Иҗтимагый советы вәкилләрен фикер алышу һәм мондый бәяләүнең нәтиҗәләрен формалаштыру өчен җәлеп итә.

3.11. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзалары саны биштән ким булмаска тиеш.

3.12. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләре Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советы рәисе карары нигезендә түбәндәге очракларда туктатыла:

-Россия Федерациясенең җинаять-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә аңа җинаять кылуда гаепләү белдерелгәндә;
-аңа административ кулга алу рәвешендә административ җәза билгеләнгәндә;
- дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органы депутатына кандидат, җирле үзидарә органында сайлау вазыйфасына кандидат, ышанычлы зат яисә сәяси партия кандидатының вәкаләтле вәкиле сыйфатында,

шулай ук аны Россия Федерациясендә референдум үткәрү буенча инициатив төркем составына кергән очракта теркәгәндә.

3.13. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләре түбәндәге очракларда туктый:

-аның вәкаләтләре чоры тәмамланганда;

-Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет составыннан чыгу турында аның тарафыннан гариза тапшырылганда;

-сәламәтлеге торышы буенча Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет эшендә катнаша алмаганда;

-аңа карата чыгарылган суд хөкеме законлы көченә кергәндә;

-законлы көченә кергән суд карары нигезендә ул хокукый сәләтсез яисә хәбәрсез юкка чыккан дип танылганда;

- аның этик нормаларны тупас бозуы аркасында-Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзалары санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителгән Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет карары буенча;

- Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышларының эшендә җитди сәбәпсез системалы рәвештә (өч тапкырдан артык) катнашмавы-Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзалары санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителгән Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет карары буенча;

- Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисе яисә рәисе урынбасарының йөкләмәләрен җитди сәбәпсез системалы рәвештә (ике тапкырдан артык) үтәмәгәндә - Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзалары санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителгән Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет карары буенча;

-ул Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасына, Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт вазыйфасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, муниципаль вазыйфага яисә муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп куелганда;

- ике гражданлык алганда;

-Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылганда;

3.14. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктату Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советы рәисе карары нигезендә, Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзасының язма гаризасы яки Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисе, урынбасарының күрсәтмәсе нигезендә, шулай ук әлеге нигезләмәнең 3.13 пунктында каралган хәлләрне ачыкланган очракта гамәлгә ашырыла.

## 4. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары

4.1. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзасы түбәндәгеләргә хокуклы:

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты инициативасы белән уздырыла торган мәдәният һәм мәгариф өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмаларның эшчәнлеген , хезмәтләр күрсәтү шартларын бәяләүгә кагылышлы барлык чараларда (утырышларда, киңәшмәләрдә, «түгәрәк өстәлләрдә» һ. б.) катнашырга, дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләр, шәхси мәгълүматлар турындагы белешмәләр булган мәгълүматтан һәм чикләнгән файдалану мәгълүматыннан файдалануга бәйле рәвештә федераль законнар нигезендә файдалану чикләнә торган чаралардан тыш;

- инициатив тәртиптә Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советка аналитик язмалар, докладлар һәм башка мәгълүмати-аналитик материаллар әзерләргә һәм җибәрергә;
- Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисе аша Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның эш планына һәм аның утырышларын үткәрү тәртибенә тәкъдимнәр кертергә;
- Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышына көн тәртибенә куелган мәсьәләләрне карауда катнашу өчен чакырылган затлар кандидатуралары буенча тәкъдимнәр кертергә;
- Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзаларыннан чыгарга.

4.2. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзасы түбәндәгеләргә бурычлы:
- Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисе йөкләмәләрен үтәргә;
- Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның әлеге Типлаштырылган нигезләмәдә каралган эш тәртибен белергә һәм үтәргә;
- Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышларында шәхсән катнашырга;
-үзенә йөкләнгән бурычларны хәл итү өчен, Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет тарафыннан төзелгән эксперт, эш төркемнәре, комиссияләр, башка эш органнары эшендә катнашырга.

5. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның эш тәртибе

5.1. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет үзенең эшен Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме буенча Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышында раслана торган планнар һәм программалар нигезендә оештыра.

5.2. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет эшен планлаштыру Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзалары, Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисе һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитет тәкъдимнәре нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.3. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышлары кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышларында кабул ителгән карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

5.4. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышлары,әгәр дә анда Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзаларының өчтән икесеннән дә ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы булып санала. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзасы,утырышта шәхси катнашу мөмкинлеге булмаган очракта, көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча үз фикерен һәм тавышын, алдан бу хакта Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисенә яисә рәис урынбасарына яки Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советының җаваплы секретаренә хәбәр итеп, Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның башка әгъзасына язмача, факсимиль яки электрон почта аша тапшырырга хокуклы. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышында катнашучы әгъзалар санына үз тавышларын Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның башка әгъзаларына ышанып тапшырган Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзалары өстәлә.

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет карарлары гади күпчелек тавыш белән кабул ителә.

5.5. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышларын Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисе, ул булмаганда Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәис урынбасары уздыра.

5.6. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисе:
- Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелек итә;

- Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышларын алып бара;
- Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзаларының тәкъдимнәре нигезендә Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның эш планнарын әзерли, шулай ук аларга үзгәрешләр кертә һәм Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советка раслау өчен тәкъдим итә;
- Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышларын оештыра;
- Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышының көн тәртибен раслый;
- Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет тәкъдимнәренә, беркетмәләренә һәм Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның башка документларына кул куя;
- Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышларын үткәрү вакытын һәм урынын билгели;
- Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет эшчәнлеге кысаларында, үзенә йөкләнгән максат һәм бурычлардан чыгып Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзаларына йөкләмәләр бирә;
- Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет исеменнән рәсми мөрәҗәгатьләр, тәкъдимнәр, җаваплар, аңлатмалар һәм мөрәҗәгатьләрне имзалый;
- Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәклебулган башка функцияләрне башкара.

5.7. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисе урынбасары:

- Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисе рәсми рәвештә булмаганда аның функцияләрен башкара;
- Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышларын әзерләүне оештыра;
- Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышларының көн тәртибен төзи һәм аны Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисенә раслауга тәкъдим итә;
- Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисе кушуы буенча Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле башка функцияләрне башкара.

5.8. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет җаваплы секретаре:
- утырышларга материаллар һәм карар проектларын әзерләүне оештыра;
- Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзаларына Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның утырыш үткәрү урыны һәм вакыты, көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле мәгълүмат-белешмә материаллар белән тәэмин итә;
- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының һәм Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның үзара хезмәттәшлеген оештыруны тәэмин итә;
- Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет эшчәнлеген документаль-техник яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыра;
- Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышларының беркетмәләрен төзи һәм кабул ителгән карарларның үтәлешен контрольдә тота;
- Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышларының көн тәртибен төзүдә катнаша.

5.9. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзалары, сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышларында тыңлауга һәм фикер алышуга мәсьәләләрне әзерләү өчен, эш, эксперт төркемнәренә һәм башка эш органнарына берләшә алалар,
материалларны әзерләүгә Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисе урынбасары белән килештереп, Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет составына кермәгән белгечләрне җәлеп итә алалар.

5.10. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет карары буенча Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышларына Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет тарафыннан карала торган мәсьәләләр буенча кирәкле белешмәләр һәм бәяләмәләр бирү өчен башкарма органнар, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты, коммерциячел булмаган оешмалар, фәнни учреждениеләр вәкилләре, экспертлар һәм башка белгечләр чакырылырга мөмкин. Массакүләм мәгълүмат чараларының Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзалары булмаган вәкилләре Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышларында Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет чакыруы буенча катнаша ала.

5.11. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет каравына кертелә торган материаллар Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисе урынбасарына Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышы билгеләнгән көнгә кадәр ун календарь көннән дә соңга калмыйча тапшырылырга тиеш. Материалларны соңрак тапшыру Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет Рәисе яки рәис урынбасары белән килештерелә.

5.12. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет эшчәнлеген оештыру-техника яктан тәэмин итүне Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты башкара.